ЛЕНИНОГОРСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018елның 13 декабре №78

Лениногорск муниципаль районы Советының 2011 елның 22 декабрендәге 88 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, раслау, теркәү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр төзелеше хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, торак төзелеше өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентлары белән формалаштырылган җир кишәрлекләрен бирүнең ачык һәм нәтиҗәле механизмын тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 44, 46 статьяларына, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск районы Советына таянып, карар кабул итте:

1. «Лениногорск муниципаль районы территориясендә җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, раслау, теркәү һәм бирү тәртибен раслау турында» 2011 елның 22 ноябрендәге 88 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, раслау, теркәү һәм бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.12.2005 № 840 карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29.12.2005 № 840 карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) гавами сервитутлар белешмәләре - ЗКП мәгълүматлары буенча;

2. «Лениногорские вести» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында урнаштырырга.

Лениногорск муниципаль районы башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Р.Г. ХӨСӘЕНОВ